**Татарский язык с Г. Кутуем**

**Гадел Кутуй**

**Тапшырылмаган хатлар** *(неотосланные письма; тапшыру — передавать; вручать)*

Пособие подготовила **Лилия Валиуллина**

*Метод чтения Ильи Франка*

БЕРЕНЧЕ ХАТ *(первое письмо)*.

Искәндәр *(Искандер)*!

Дусларча язылган җылы хатың өчен рәхмәт *(за дружески написанное теплое письмо спасибо; дус — друг; язу — писать; хат — письмо)*. Мин аны кат-кат укып чыктым *(я его неоднократно перечла: «прочитав перешла»; уку — читать; чыгу — переходить)*. Бу сагыну хатыңны укыган чакта *(этого тоскливого /твоего/ письма во время чтения; чак — время)*, минем күз алдымда аерылышкан көннәрдәге *(перед моими глазами в расставания дни; алда — впереди; аерылу — расставаться; көн — день)* тар холыклы, бозык күңелле Искәндәр түгел *(не с ограниченным нравом, испорченной душой Искандер)*, бәлки моннан 8 ел элек *(но от этого /времени/ 8 лет назад)*: «Сезнең чәчегез нинди йомшак, нәфис» *(ваши волосы такие мягкие, красивые; чәч — волосы)*, — дип

килеп танышкан Искәндәр иде *(сказав, подошедший знакомиться: «подойдя познакомившийся», Искандер был; дию — говорить; килү — приходить; танышу —знакомиться)*.

Нинди матур истәлек *(какая красивая память)*! Әйе, минем беренче мәхәббәтем дә *(да, моя первая любовь тоже)*, кешеләр белән аралаша башлаудан туган беренче шатлыгым да *(и от завязывания общения с людьми рожденная первая радость; кеше — человек; аралашу — общаться; башлану — начинаться; завязываться)*, сиңа, синең белән танышу вакытына барып бәйләнә *(к тебе, с тобой знакомства ко времени привязано: «пойдя, связывается»; бару — идти; бәйләнү — привязываться; связываться)*. Миндә яңа хисләр тудырган *(во мне новые чувства породивший; тудыру — рождать)*, күңел күзләремә матурлык буяулары биргән *(души глазам красоты краски давшие)* бу кадерле минутларны мин бик еш искә төшерәм *(эти дорогие минуты я очень часто вспоминаю; ис — память; искә төшерү — вспоминать)*. Тормышның тис-коре *(если с жизни отрицательными)*, усал, шакшы яклары белән көрәшкәндә туңсам, арысам әгәр, *(злыми, грязными сторонами в борьбе застыну, устану; тормыш — жизнь; көрәш — борьба; туңу — замерзать, застывать; ару — уставать)* — шул рәхәт минутларны хәтерләп җылынам һәм көч җыям *(эти блаженные минуты вспомнив, согреваюсь, и силы собираю; хәтерләү — вспоминать; җыю — собирать)*.

Исеңдәме беренче танышуыбыз *(в памяти ли /наше/ первое знакомство)*?

**Искәндәр!**

**Дусларча язылган җылы хатың өчен рәхмәт. Мин аны кат-кат укып чыктым. Бу сагыну хатыңны укыган чакта, минем күз алдымда аерылышкан көннәрдәге тар холыклы, бозык күңелле Искәндәр түгел, бәлки моннан 8 ел элек: «Сезнең чәчегез нинди йомшак, нәфис», — дип килеп танышкан Искәндәр иде.**

**Нинди матур истәлек! Әйе, минем беренче мәхәббәтем дә, кешеләр белән аралаша башлаудан туган беренче шатлыгым да, сиңа, синең белән танышу вакытына барып бәйләнә. Миндә яңа хисләр тудырган, күңел**

**күзләремә матурлык буяулары биргән бу кадерле минутларны мин бик еш искә төшерәм. Тормышның тис-коре, усал, шакшы яклары белән күрәшкәндә туңсам, арысам әгәр — шул рәхәт минутларны хәтерләп җылынам һәм көч җыям.**

**Исеңдәме беренче танышуыбыз?**

Мин, матурлыкның нәрсә икәнен бары хыялда гына күреп *(я, видев красоту только в мечтах: «красоты что такое только в мечтах видев»; күрү — видеть)*, әкиятләрдән генә ишетеп килгән ятимә бер кыз *(из сказок только слышавшая осиротевшая девочка; ишетү — слышать; килү — приходить)*, кинәт өнемдә чын матурлык диңгезенә чумдым *(внезапно наяву в море настоящей красоты окунулась; өн — явь; диңгез — море; чуму — нырять)*, шатлык дулкыннарында йөзә башладым *(на волнах радости плавать начала; дулкын — волна)*. Чынлап та, корып, саргаеп беткән яз чәчәгеп *(действительно, засохший, пожелтевший весенний цветок; кору — засохнуть; саргаю — желтеть; бетү — кончаться)* иң тәмле хуш исләр чыгарып торган чәчәккә әйләндерү *(в испускающий самые вкусные ароматные запахи цветок превратить; чыгару — выводить; испускать; тору — быть)* — охшашы булмаган матурлык бит *(/ни на что/ не похожая красота ведь; охшаш — похожий; булу — быть)*. Үземне, гомумән, кешеләрне чәчәккә тиңләштерү дөрес үк булмаса да *(хоть себя, в целом, людей с цветами отождествление правильно не будет)*, ләкин минем хәл ул чагында шуңа бик якын иде *(но мое состояние в то время к этому очень близко было)*.

Мин элекке Кузнецк өязендә, караңгы мишәр авылында — Ялгашта тудым *(я в бывшем Кузнецком уезде, темной мишарской деревне — Ялгаше родилась; мишәр — одна из групп татарского народа)*. Минем атамның гомер-гомергә күргәне бары биш-алты авыл булган *(у моего отца за всю жизнь увиденного всего пять-шесть деревень было)*. Ә мин — аның кызы — Мәскәүдә тордым, Ленинградта булдым, Харьков, Ташкент, Бакуны күрдем *(а я — его дочь — в Москве жила, в Ленинграде была, Харьков, Ташкент, Баку видела)*... Мин диңгездә йөздем, Кавказ тауларына мендем *(я в море плавала, на горы Кавказа поднималась; тау — гора; менү — подниматься)*. Минем атам үз телен дә

кирәгенчә белмәгән *(мой отец даже свой язык толком не знал; кирәк — необходимо)*. Ә мин — аның кызы — татарча гына түгел, рус, немец телләрендә дә сөйләшәм *(а я — его дочь — не только по-татарски, но и на русском, немецком языках говорю; сөйләшү — разговаривать)*. Минем атам бөтен гомерен көтүчелектә, газап-михнәт эчендә уздырган *(мой отец всю жизнь в пастушестве, в страданиях-нужде провел; уздыру — проводить)*, үлгәндә дә сарыклар арасында үлгән *(и среди овец умер: «умирая среди овец умер»; үлү — умирать)*. Ул бик еш сырхаулаган, ләкин бер генә тапкыр да докторны күрмәгән *(он очень часто болел, но даже одного раза доктора не видел; сырхаулау — болеть)*. Ә мин — Чулак Фәхри кызы — хәзер үзем доктор *(а я — дочь Однорукого Фахри — сейчас сама доктор)*.

**Мин, матурлыкның нәрсә икәнен бары хыялда гына күреп, әкиятләрдән генә ишетеп килгән ятимә бер кыз, кинәт өнемдә чын матурлык диңгезенә чумдым, шатлык дулкыннарында йөзә башладым. Чынлап та, корып, саргаеп беткән яз чәчәген иң тәмле хуш исләр чыгарып торган чәчәккә әйләндерү — охшашы булмаган матурлык бит. Үземне, гомумән, кешеләрне чәчәккә тиңләштерү дөрес үк булмаса да, ләкин минем хәл ул чагында шуңа бик якын иде.**

**Мин элекке Кузнецк өязендә, караңгы мишәр авылында — Ялгашта тудым. Минем атамның гомер-гомергә күргәне бары биш-алты авыл булган. Ә мин — аның кызы — Москвада тордым, Ленинградта булдым, Харьков, Ташкент, Бакуны күрдем... Мин диңгездә йөздем, Кавказ тауларына мендем. Минем атам үз телен дә кирәгенчә белмәгән. Ә мин — аның кызы — татарча гына түгел, рус, немец телләрендә дә сөйләшәм. Минем атам бөтен гомерен көтүчелектә, газап-михнәт эчендә уздырган, үлгәндә дә сарыклар арасында үлгән. Ул бик еш сырхаулаган, ләкин бер генә тапкыр да докторны күрмәгән. Ә мин — Чулак Фәхри кызы — хәзер үзем доктор.**

Зур тормышны чын-чынлап белү һәм шуны белгәннән соң *(большую жизнь в действительности зная и после этого знания)* киң сулыш алып эшләү *(широкое*

*дыхание взяв, работать; алу — брать)* шатлыгын, яшисе килү матурлыгын аңлату кыен *(радость, красоту желания жить объяснить трудно; яшү — жить)*. Миңа әле күптән түгел бер яңа роман укырга туры килде *(мне еще недавно один новый роман читать довелось; туры — прямо; килү — приходить)*. Бу китап миңа әйтеп бетергесез сөенеч, ләззәт бирде *(эта книга мне необъяснимую радость, вкус дала; әйтү — говорить; бетерү — заканчивать)*. Чөнки хәзер доктор булган татар кызының нәселе дә *(потому что и поколение татарской девушки, сейчас ставшей доктором; нәсел — поколение, род)*, тормыш төбеннән югарыга, язучылык дәрәҗәсенә күтәрелгән язучының нәселе кебек үк *(как и поколение со дна жизни наверх, на писательский уровень поднявшегося писателя; төп — дно; дәрәҗә — уровень; күтәрелү — подниматься)*, иске заман бизгәгендә *(/это/ в старого времени лихорадке; бизгәк — лихорадка)*, җәфа чигү утында яшәгән нәсел *(в огне мучений жившее поколение; җәфа — мучение; чигү — мучаться ут — огонь; яшәү — жить)*.

Әйе, беренче танышуыбыз *(да, первое /наше/ знакомство)*! Тәртипсез язуым өчен гафу ит, иркәм *(за беспорядочное письмо извини, ласковый /мой/)*. Минем өчен тормыш хәзер шундый бай, шундый күңелле *(для меня жизнь сейчас такая богатая, такая веселая)*, бер әйбер турында яза башладым исә *(как только об одной вещи писать начала)*, берсе-берсеннән матур булган тойгылар, фикерләр кәгазьгә агылырга гына торалар *(один за другим красивее чувства, мысли на бумагу излиться готовы; тору — стоять; находиться)*. Менә хәзер дә үзем сиңа хат язам, үзем радио аркылы Шубертның «Язылып бетмәгән симфония»сен тыңлыйм *(вот и сейчас сама тебе письмо пишу, сама по радио Шуберта «Незаконченную симфонию» слушаю; бету — заканчиваться; тыңлау — слушать)*. Бу симфониядә нинди генә авазлар юк *(в этой симфонии каких только звуков нет)*! Акрын, бик акрын башланган музыкаль тавышлар *(тихо, очень тихо начавшиеся музыкальные звуки; башлану — начинаться)* йомшак, ягымлы күченүләр белән *(мягкими, ласковыми переходами; күчену — переезжать, переходить)* зур зилзиләләргә житә... тына... тагын күтәрелә *(до больших сотрясений достигают… стихают… снова усиливаются; зилзилә — землетрясение; җиту — достигать; тыну — замолкать; күтәрелү —*

*поднима́ться; усиливаться)*. Йөрәк тә музыкага кушылып тибә башлый *(и сердце, к музыке присоединившись, стучать начинает; кушылу — соединяться; тибенү — пинаться)*. Гафу ит, Искәндәр *(извини, Искандер)*. Шубертны тыңлап бетермичә, хатымны дәвам итә алмыйм *(Шуберта не дослушав, письмо продолжить не смогу; бетерү — заканчивать; дәвам итү — продолжать; алу — мочь; быть в состоянии)*. Янымда утырган җиде яшьлек Кадриям дә *(и рядом сидящая /моя/ семилетняя Кадрия; ян — бок; утыру — сидеть)*:

**Зур тормышны чын-чынлап белү һәм шуны белгәннән соң шатлыгын, яшисе килү матурлыгын аңлату кыен. Миңа әле күптән түгел бер яңа роман укырга туры килде. Бу китап миңа әйтеп бетергесез сөенеч, ләззәт бирде. Чөнки хәзер доктор булган татар кызының нәселе дә, тормыш төбеннән югарыга, язучылык дәрәҗәсенә күтәрелгән язучының нәселе кебек үк, иске заман бизгәгендә, җәфа чигү утында яшәгән нәсел.**

**Әйе, беренче танышуыбыз! Тәртипсез язуым өчен гафу ит, иркәм. Минем өчен тормыш хәзер шундый бай, шундый күңелле, бер әйбер турында яза башладым исә, берсе-берсеннән матур булган тойгылар, фикерләр кәгазьгә агылырга гына торалар. Менә хәзер дә үзем сиңа хат язам, үзем радио аркылы Шубертның «Язылып бетмәгән симфония»сен тыңлыйм. Бу симфониядә нинди генә авазлар юк! Акрын, бик акрын башланган музыкаль тавышлар йомшак, ягымлы көченүләр белән зур зилзиләләргә җитә... тына... тагын күтәрелә. Йөрәк тә музыкага кушылып тибә башлый. Гафу ит, Искәндәр. Шубертны тыңлап бетермичә, хатымны дәвам итә алмыйм. Янымда утырган җиде яшьлек Кадриям дә:**

— Әнкәем, шундый матур музыка... ә син тыңламыйсың, — дип тора *(мамочка, такая красивая музыка… а ты не слушаешь, — говорит)*. Улым Рафаэль йоклый *(/мой/ сын Рафаэль спит; йоклау — спать)*. Нинди тыныч йоклый ул *(как спокойно спит он)*! Рафаэль дә, синең кебек үк, учларын яңак астына куеп йоклый *(Рафаэль тоже, как ты, ладони под щеку положив, спит; уч — ладонь; аста — внизу; кую — класть)*. Әнә ул төшендә нәрсәгәдер матур итеп

елмайды *(вот он во сне чему-то красиво улыбнулся; төш — сон; елмаю — улыбаться)*. Ә без аналы-кызлы, Кадрия беләп икәү, Шубертны тыңлыйбыз *(а мы, мама с дочкой, с Кадрией вдвоем Шуберта слушаем)*. Хәер, Кадрия нәрсә уйлый торгандыр — белмим *(впрочем, Кадрия о чем думает — не знаю; уйлау — думать; тору — быть, находиться; белү — знать)*. Ул бик акыллы булды *(она очень умной стала)*. Күпне белә башлады *(многое знать начала)*. Шулай да бала күңелен аңламассың *(хотя ребенка душу не понять; аңлау — понимать)*: йә «Әткәем ник озак кайтмый?» *(или «Папочка почему долго не возвращается»; кайту — возвращаться)*, йә «Әнкәем иртәгә нәрсә китерер икән?» — дип уйлана торгандыр *(или «Мамочка завтра что принесет?» — размышляет /наверное/; китерү — приносить; дию — говорить; тору — здесь вспом.глагол, означает повторяемость, длительность и регулярность действия)*. Без Шубертны эндәшмичә тыңлыйбыз *(мы Шуберта, не разговаривая, слушаем; эндәшү — обращаться; разговаривать)*. Бу музыкада сагыну моңы да *(в этой музыке и мелодия тоски; моң — мелодия, печаль)*, ярату-яратмау тавышы да *(и любви-нелюбви звуки)*, җил-давыл да — бар да бар *(и ветер-буря — все есть)*. Рәхәтләнеп тыңлыйм әле *(с наслаждением послушаю-ка; рәхәт — наслаждение)*. Үзәк калалардан бик ерак урнашкан Әдрәс авылында Шуберт симфониясе аеруча матур яңгырый *(от центральных городов /в/ очень далеко расположенной деревне Адрас симфония Шуберта особенно красиво звучит; кала — город; урнашу — располагаться; яңгырау — звучать)*.

Шатлыклы туган илем *(радостная родная страна)*! Шуберт, Бетховен шикелле композиторларның иң тирән моңнарын *(вроде Шуберта, Бетховена композиторов самые глубокие мелодии)* ерак авылларга ишеттерүең өчен *(за возможность услышать в дальних деревнях: «дальним деревням дать услышать»; ишеттерү — дать услышать)* сиңа җылы рәхмәт яусын *(на тебя теплая благодарность пусть прольется; яву — сыпаться, проливаться)*.

**— Әнкәем, шундый матур музыка... ә син тыңламыйсың, — дип тора. Улым Рафаэль йоклый. Нинди тыныч йоклый ул! Рафаэль дә, синең кебек үк, учларын яңак астына куеп йоклый. Әнә ул төшендә нәрсәгәдер матур**

**итеп елмайды. Ә без аналы-кызлы, Кадрия белән икәү, Шубертны тыңлыйбыз. Хәер, Кадрия нәрсә уйлый торгандыр — белмим. Ул бик акыллы булды. Күпне белә башлады. Шулай да бала күңелен аңламассың: йә «Әткәем ник озак кайтмый?», йә «Әнкәем иртәгә нәрсә китерер икән?» — дип уйлана торгандыр. Без Шубертны эндәшмичә тыңлыйбыз. Бу музыкада сагыну моңы да, ярату-яратмау тавышы да, җил-давыл да — бар да бар. Рәхәтләнеп тыңлыйм әле. Үзәк калалардан бик ерак урнашкан Әдрәс авылында Шуберт симфониясе аеруча матур яңгырый.**

**Шатлыклы туган илем! Шуберт, Бетховен шикелле композиторларның иң тирән моңнарын ерак авылларга ишеттерүең өчен сиңа җылы рәхмәт яусын.**

Искәндәр!

Хатымны дәвам итәм *(/свое/ письмо продолжаю)*.

1923 ел иде *(1923 год был)*. Аяусыз тормыш камчысы астында төрле шәһәр, авылларны гизеп туйганнан соң *(под безжалостной жизни плетью в разных городах, деревнях наскитавшись вдосталь; гизү — путешествовать; тую — насытиться)*, мин Казанга килеп чыктым *(я до Казани добралась; чыгу — выбираться)*. Казанда университет рабфагына укырга кердем *(в Казани на университетский рабфак учиться пошла; уку — учиться)*. Бу рабфак ул елларны университет белән бер бинада урнаша иде *(этот рабфак в те годы с университетом в одном здании располагался)*.

Беренче дәресләрне тыңлау белән үк *(первые же уроки прослушав)*, мин бәхеттән, шатлыктан, нәрсәгә тотынырга белмичә, шашып йөри башладым *(я от счастья, радости, за что взяться не зная, с азартом ходить начала; тотыну — браться; шашып — с азартом, исступлением; йөрү — ходить)*. Рабфакка барганда да, кайтканда да бик еш *(на рабфак и идя, и возвращаясь, очень часто; бару — идти; кайту — возвращаться)*: «Шушы урамнар, шушы коридорлар буйлап кайчандыр китап, дәфтәр тотып Ленин йөргән *(по этим улицам, этим коридорам когда-то книги, тетради держа, Ленин ходил; буйлап — по, вдоль)*, шул бинада Толстой укыган *(в этом здании Толстой учился)*. Шунда укырга дип,

яшь Горький хыял корган *(/чтобы/ здесь учиться, молодой Горький мечты строил; кору — строить)*. Шул бинадан дөньяның атаклы галимнәре чыккан *(из этого здания мировые знаменитые ученые вышли)*. Мин укый торган бүлмәләрдә аларның да тавышлары яңгыраган», — дип уйлана башладым *(в моих учебных комнатах и их голоса звучали» — размышлять начала; уйлану — размышлять)*. Рус әдәбияты буенча кергән укытучы Морозов та беренче лекциясен шул фикерләр белән башлады *(по русской литературе вошедший преподаватель Морозов тоже первую лекцию с этих мыслей начал; керү — входить; вступать)*.

Ә кайчагында университетның ап-ак колонналарына сөялә идем дә *(а иногда к университетским белоснежным колоннам прислонялась; сөялү — прислоняться)*, башымны югары күтәреп: «Иптәшләр, күрәсезме мин нинди бәхетле... *(и голову высоко подняв: «Товарищи, видите ли, я какая счастливая…)* Мин — Чулак Фәхри кызы — Ленин... Толстой укыган йортта укыйм» *(я — Однорукого Фахри дочь — в доме, где учились Ленин… Толстой, учусь; йорт — дом)*, — дип кычкырып, бик каты кычкырып җибәрәсем килә иде *(закричать, очень громко закричать хотелось: «закричав, очень громко закричав, выпустить хотелось»; кычкыру — кричать; җибәрү — выпускать)*.

**Искәндәр!**

**Хатымны дәвам итәм.**

**1923 ел иде. Аяусыз тормыш камчысы астында төрле шәһәр, авылларны гизеп туйганнан соң, мин Казанга килеп чыктым. Казанда университет рабфагына укырга кердем. Бу рабфак ул елларны университет белән бер бинада урнаша иде.**

**Беренче дәресләрне тыңлау белән үк, мин бәхеттән, шатлыктан, нәрсәгә тотынырга белмичә, шашып йөри башладым. Рабфакка барганда да, кайтканда да бик еш: «Шушы урамнар, шушы коридорлар буйлап кайчандыр китап, дәфтәр тотып Ленин йөргән, шул бинада Толстой укыган. Шул бинадан дөньяның атаклы галимнәре чыккан. Мин укый торган бүлмәләрдә аларның да тавышлары яңгыраган», — дип уйлана башладым.**

**Рус әдәбияты буенча кергән укытучы Морозов та беренче лекциясен шул фикерләр белән башлады.**

**Ә кайчагында университетның ап-ак колонналарына сөяләә идем дә, башымны югары күтәреп: «Иптәшләр, күрәсезме мин нинди бәхетле... Мин — Чулак Фәхри кызы — Ленин... Толстой укыган йортта укыйм», — дип кычкырып, бик каты кычкырып җибәрәсем килә иде.**

Шушындый бөеклеккә ашуыма, тормышка юл табуыма мин шат идем *(такого величия достижению, жизни дороги нахождению я рада была; ашу — достигать; табу — находить)*. Ул елларны тормыш минем өчен ал да гөл генә *(в те годы жизнь для меня розовой и цветочной только)*, бөтен бәхетләр бергә, минем йөрәгемә җыелгандай тоела иде *(все блага вместе в моем сердце собрались, казалось; тою — ощущать, чувствовать)*. Мин бары тик ирек, матурлык көчен генә хис иттем *(я только свободы, красоты силу чувствовала; көч — сила; хис — чувство, эмоция)*. Мин үземне чәчәкле бакчада күрдем *(я себя в полном цветов саду видела; чәчәк — цветок)*. Бер сынык икмәк белән ике бәрәңге ашап *(один кусок хлеба и две картофелины поев; ашау — есть)*, алтышар сәгать дәрес тыңларга туры килгәндә дә, мин шат һәм көләч идем *(по шесть часов уроки слушать приходилось когда даже, я веселая и смешливая была; туры килү — приходиться, доводиться)*. Чөнки мин күзләремне киләчәкне күрергә өйрәтә башладым *(потому что я /свои/ глаза будущее видеть обучать начала; өйрәтү — обучать)*. Ә киләчәкне күрү, шуны күрәм дип хис итү *(а будущее видеть, ощущение, что видишь это: «это вижу, говоря, чувствовать»)* иң авыр минутларны да җиңел һәм күркәм итә *(и самые тяжелые минуты легкими и прелестными делает)*.

Менә шунда, бәхеттән шашып рәхәттә йөргән чагымда, мин сине очраттым *(вот там, от счастья обезумев, в наслаждении пребывая: «в наслаждении хождения времена», я тебя повстречала)*, һәрбер сөю һәм сөелүнең: — «Эх, яратасы иде, сөясе... сөеләсе иде» *(каждой любви и влюбленности: — «Эх, полюбить бы, любить… влюбиться бы»; ярату — любовь, любить; сөю — любовь, полюбить)*, — дип, хисләр ташкан чагы була *(такие чувства вынашивая,*

*время было; ташу — носить)*. Алмагач та, тула һәм пешә башлагач *(и яблоня, наливаться и созревать начиная; тулу — наполняться; пешү — зреть, поспевать)*, хуш исле алмаларын җиргә ыргытып, җир белән шаяра башлый *(ароматные яблоки на землю сбросив, с землей забавляться начинает; хуш — ароматный; ис — запах; ыргыту — бросать; шаяру — шалить, забавляться)*. Шомырт та чәчәк ата *(и черемуха цветет; чәчәк — цветок; ату — извергать, выбрасывать)*. Сандугачлар да сайраша *(и соловьи щебечут; сайрау — петь, щебетать)*. Чияләр дә вакыты җиткәч кызаралар, тулылыктан матураялар *(и вишни, когда время приходит, краснеют, наливаясь, хорошеют; кызару — краснеть; матураю — хорошеть, становиться красивым)*. Мин дә үземнең матурлык тойгыларыма тулганымны сиздем *(я тоже осознала всю полноту своей красоты: «я тоже своей красоты ощущениями наполненность осознала»; тойгы — ощущение; сизү — чувствовать, осознавать)*. Минем дә яратасым, яраткан кешем белән *(мне тоже любить, с любимым человеком)*: «Без нинди бәхетле, безгә шундый рәхәт» *(мы такие счастливые, нам так хорошо)*, — дип, тын беткәнче кочышасым килде *(говоря, пока дыхание не закончится, обниматься хотелось; кочау — обнимать)*.

**Шушындый бөеклеккә ашуыма, тормышка юл табуыма мин шат идем. Ул елларны тормыш минем өчен ал да гөл генә, бөтен бәхетләр бергә, минем йөрәгемә җыелгандай тоела иде. Мин бары тик ирек, матурлык көчен генә хис иттем. Мин үземне чәчәкле бакчада күрдем. Бер сынык икмәк белән ике бәрәңге ашап, алтышар сәгать дәрес тыңларга туры килгәндә дә, мин шат һәм көләч идем. Чөнки мин күзләремне киләчәкне күрергә өйрәтә башладым. Ә киләчәкне күрү, шуны күрәм дип хис итү иң авыр минутларны да җиңел һәм күркәм итә.**

**Менә шунда, бәхеттән шашып рәхәттә йөргән чагымда, мин сине очраттым, һәрбер сөю һәм сөелүнең: — «Эх, яратасы иде, сөясе... сөеләсе иде», — дип, хисләр ташкан чагы була. Алмагач та, тула һәм пешә башлагач, хуш исле алмаларын җиргә ыргытып, җир белән шаяра башлый. Шомырт та чәчәк ата. Сандугачлар да сайраша. Чияләр дә вакыты җиткәч**

**кызаралар, тулылыктан матураялар. Мин дә үземнең матурлык тойгыларыма тулганымны сиздем. Минем дә яратасым, яраткан кешем белән: «Без нинди бәхетле, безгә шундый рәхәт», — дип, тын беткәнче кочышасым килде.**

Озак вакыт үтмәде — студентлар арасында зур кичәгә әзерлек репетицияләре башланды *(много времени не прошло — между студентами к большому вечеру подготовительные репетиции начались; үтү — проходить; ара — промежуток; әзерләнү — готовиться)*. Ул елларны мин рабфакның Островский урамындагы тулай торагында тора идем *(в те годы я на улице Островского в рабфаковском общежитии жила)*. Без бер бүлмәдә биш кыз тордык *(мы в одной комнате пять девушек жили)*. Без бишәвебез биш төрле милләттән булсак та *(мы все пятеро пяти разных национальностей были хоть)*, безнең арадагы революция туганлыгы *(между нами революции родство; туганлык — родство)* җыр белән дә әйтеп бирә алмаслык дәрәҗәдә тирән иде *(песней даже не передать было уровень взаимопроникновения: «рассказать невозможно на /каком/ уровне глубины было»; әйтү — сказать; бирү — дать; алу — мочь, быть способным; тирән — глубина /в разных значениях/)*.

Без күбрәк киләчәкне уйларга яратабыз *(мы больше о будущем думать любим)*. Бүгенгенең матурлыгы, киләчәкнең тагын да сокландырырлык булуы аркасында *(сегодняшнего дня красоте, будущего еще более восхитительному бытию благодаря; сокландыру — приводить в восторг; булу — быть; аркасында — из-за, благодаря)*, үткән заманны күздән кичерергә бик аз вакыт кала *(прошлое время перед глазами пережить очень мало времени остается; кичерү — пережить)*. Ә уйлана башласаң — чәчләр агара *(а размышлять начнешь — волосы поседеют)*. Элек, 17 нче елга хәтле Казан университетының йөзьеллык тарихында без бары биш-алты гына татар студенты күрәбез *(раньше, до семнадцатого года в Казанском университете за столетнюю историю мы всего пять-шесть татарских студентов видим; йөз — сто; ел — год)*. Ун елга бер татар студенты да туры килми *(на 10 лет одного татарского студента даже не приходится)*. Болары да аксөяк нәселеннән *(и эти из белокостного рода; ак —*

*белый; сөяк — кость; нәсел — род, поколение)*. Ә хәзер анда ярты мең татар студенты укый *(а сейчас там половина тысячи татарских студентов учится)*.

**Озак вакыт үтмәде — студентлар арасында зур кичәгә әзерлек репетицияләре башланды. Ул елларны мин рабфакның Островский урамындагы тулай торагында тора идем. Без бер бүлмәдә биш кыз тордык. Без бишәвебез биш төрле милләттән булсак та, безнең арадагы революция туганлыгы җыр белән дә әйтеп бирә алмаслык дәрәҗәдә тирән иде.**

**Без күбрәк киләчәкне уйларга яратабыз. Бүгенгенең матурлыгы, киләчәкнең тагын да сокландырырлык булуы аркасында, үткән заманны күздән кичерергә бик аз вакыт кала. Ә уйлана башласаң — чәчләр агара. Элек, 17 нче елга хәтле Казан университетының йөзьеллык тарихында без бары биш-алты гына татар студенты күрәбез. Ун елга бер татар студенты да туры килми. Болары да аксөяк нәселеннән. Ә хәзер анда ярты мең татар студенты укый.**

---

*Полностью книгу можно купить на сайте www.franklang.ru в соответствующем языковом разделе (татарский язык), в подразделе «Тексты на татарском языке, адаптированные по методу чтения Ильи Франка»*